ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 10 марты**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 03-03-543**

Зеленодольск шәһәре-Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселок кишәрлегендә Идел елгасы аша боз кичүен ябу турында

Язгы чор башлану уңаеннан, уңай температура һәм кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре-Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселок кишәрлегендә Идел елгасы аша боз кичүен 2016 елның 08 мартыннан иртәнге сәгать 10.00 ябарга.
2. Зеленодольск муниципаль районы һәм Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселок Башкарма комитетлары җитәкчеләренә, ШЭ Р.А.Миңнуллинга (судан файдаланучы) боз кичүе буенча транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен туктату буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә:
   -киртәләр корырга;
   -куркыныч турында кисәтү билгеләрен билгеләргә;
   -күрсәткечләр билгеләргә.
3. Зеленодольск районы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ тарафыннан автотранспортның бозга чыгуына юл куймау буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.
4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А. Н.Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.
5. 2015 елның 28 ноябрендәге 2575 номерлы “2015-2016 кышкы чорда боз кичүеннән файдаланганда кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен, контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.О. Котельниковка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин